**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.04.2023 № 186-осн

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 25 июлендәге 386-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 февралендәге 91 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» 2018 елның 25 июлендәге 386-осн номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 9 мартындагы 153-осн номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Юридик бүлек җитәкчесенә (В.В.Мәнихова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары И.Н.Зариповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 11 апрелендәге 186-осн номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» 2018 елның 25 июлендәге 386-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә кертелә торган үзгәрешләр

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып рәсми басылып чыккан Министрлыкның норматив актлары, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм алар хакында иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштыру өчен бердәм төбәк интернет-порталында (алга таба – бердәм төбәк интернет-порталы) билгеләнгән мәгълүмат ресурсында (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырылган Министрлыкның норматив актлары проектлары, Министрлыкта эшләнгән актларның проектлары тора.

4.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру максатларында норматив хокукый акт проекты урнаштырылган срок чикләрендә килгән бәяләмә килгән көненнән соңгы эш көненнән соңга калмыйча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының ведомствоара электрон документ әйләнешенең бердәм системасында теркәлә.»;

4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә киңәш итү холкына ия һәм, әлеге Тәртипнең 4.5.1 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, алынган көненнән башлап 15 көнлек срокта Министрлык тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

Карау нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны уздыручы юридик яисә физик затка мотивлаштырылган җавап (бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторлар турында мәгълүмат яки ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысулы турында тәкъдим булмаган очраклардан тыш) җибәрелә, анда коррупциягә каршы бәйсез экспертизаның исәпкә алынган нәтиҗәләре һәм (яки) норматив хокукый актта яисә норматив хокукый акт проектында ачыкланган коррупциячел фактор белән риза булмау сәбәпләре чагылдырыла.»;

түбәндәге эчтәлектәге 4.5.1-4.5.2 пунктлары белән тулыландырырга:

«4.5.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча түбәндәге бәяләмәләр каралырга тиеш түгел:

норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру буенча экспертлар сыйфатында Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында аккредитацияләнмәгән юридик затлар һәм физик затлар тарафыннан әзерләнгән;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы раслаган формага туры килми торган.

4.5.2. 4.5.1 пунктның өченче абзацында күрсәтелгән очракта, Министрлыкның структур бүлекчәсе мондый бәяләмәне теркәгән көннән башлап 15 көн узганчы, сәбәпләрен күрсәтеп, кайтарып бирә.»;

4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу әлеге Тәртипнең 4.5 - 4.5.2 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.».